| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**09.03.2016** № **04-14-33**

Казан ш.

Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәткәрләре вазифага кагылышлы бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагын чыгара яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну тудырган хәбәрләре тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 22 декабрендәге “Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазифасын, федераль дәүләт хезмәтен башкаручы һәм башка затларның вазифадагы бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагын чыгарган яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну тудырган хәбәрләре тәртибе һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” 650нче Указы белән б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәткәрләре вазифага кагылышлы бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагын чыгара яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну тудырган хәбәрләр тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетында кадрлар эшен оештыру һәм башкару өчен җаваплы булган затка Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетының хезмәткәрләрен әлеге Тәртип белән таныштырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлеше үз күзәтчелегем астында кала.

Рәис О.А. Редько

Татарстан Республикасы
сатып алулар бенча
Дәүләт комитетының
___________елның ______санлы
боерыгы белән расланган

**Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы дәүләт граждannар хезмәткәрләре вазифага кагылышлы бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагын чыгара яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну тудырган хәбәрләрен хәбәр итү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең (алда – гражданлык хезмәткәрләре, Дәүләт комитеты) вазифадагы бурычын үтәгәндә яклар арасында чыккан яисә чыгарга мөмкин булган бәхәсләр белән шәхси кызыксыну барлыкка килү турында Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитеты рәисе мәнфәгатьләрен күрсәтүче вәкиленә (алда – рәис) хәбәр итү процедурасы регламентын билгели.

2. Гражданлык хезмәткәре тарафыннан вазифадагы бурычын үтәгәндә яклар арасында чыккан яисә чыгарга мөмкин булган бәхәсләр белән шәхси кызыксыну барлыкка килү турында хәбәр әлеге Тәртип кушымтасында күрсәтелгәнчә, язма формада төзелеп (алда – хәбәрнамә), Дәүдәт комитеты рәисенә җибәрелә.

3. Дәүләт комитеты рәисе өч көн эчендә хәбәрнамәне коррупцион яисә башка төрле хокук бозулар профилактикасы буенча эш өчен җаваплы затка якынча карауга җибәрә (алда – җаваплы зат).

4. Хәбәрнамәне якынча карау барышында җаваплы затның хәбәрнамә җибәргән гражданлык хезмәткәреннән күрсәтелгәннәр буенча аңлатма сорап алырга, дәүләт власте органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынган оешмаларга билгеле тәртиптә запрослар җибәрергә хокукы бар.

5. Хәбәрнамәне якынча карау нәтиҗәләре буенча җаваплы зат үз аңлатмасын әзерли. Якынча карау барышында алынган хәбәрнамә, нәтиҗә һәм башка материалларны җаваплы зат хәбәрнамәне алган көннән алып җиде көн эчендә Дәүләт комитетының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм яклар бәхәсләрен көйләү буенча Комиссиясе рәисенә (алда – Комиссия) җибәрә.

6. Белдерүләрне алдан карау барышында ясалган нәтиҗә һәм башка материаллар Дәүләт Комитеты рәисенә Дәүләт Комитеты Комиссиясенә белдерү кергән көннән алып җиде эш көне эчендә бирелә. Әлеге Тәртипнең 4нче пунктында күрсәтелгән запросларны җибәргән очракта, нәтиҗәләр һәм башка материаллар Дәүләт Комитеты рәисенә Комиссиягә белдерү кергән көннән алып 45 көн эчендә бирелә. Әлеге срок озайтылырга мөмкин, әмма ул 30 көннән артмаска тиеш.

7. Хәбәрнамә, нәтиҗә һәм башка материалларны Комиссия Татарстан Республикасы сатып алулар буенча Дәүләт комитетының 2015 елның 6нчы июлендәге 09-16-88 санлы әмере белән расланган Татарстан Республикасы сатып алулар һәм мәнфәгатьләр низагын җайга салу буенча Дәүләт комитетының гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм яклар бәхәсләрен көйләү буенча Комиссиясе Нигезләмәсенә ярашлы рәвештә карый.

Татарстан Республикасы сатып алулар буенча
Дәүләт комитетының Татарстан Республикасы
дәүләт гражданнархезмәткәрләре вазифага кагылышлы
бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагын чыгара
яисә чыгарырга мөмкин булган шәхси кызыксыну тудырган
хәбәрләр тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы
сатып алулар буенча
Дәүләт комитеты рәисенә
______________________________________
______________________________________
(Ф.И.О., вазыйфа атамасы)

**Вазифадагы бурычны үтәгәндә**
**мәнфәгатьләр низагларын чыгара алган**
**яисә чыгарырга мөмкин булганнар белән шәхси кызыксынуым турында**
**ХӘБӘРНАМӘ**

Вазифа бурычын үтәгәндә мәнфәгатьләр низагларын чыгара алган яисә чыгарырга мөмкин булганнар белән шәхси кызыксынуым турында хәбәр итәм (кирәклесе астына сызарга).

Шәхси кызыксыну тудырган сәбәпләр: ________________________________________
______________________________________________________________________

Үтәү барышына шәхси кызыксыну тәэсир иткән яисә тәэсир итә алган вазифадагы бурычлар:______________________________________________________________
______________________________________________________________________

Мәнфәгатьләр низагларын булдырмый калу яисә юкка чыгару буенча тәкъдим ителгән чаралар:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Татарстан Республикасы сатып алулар һәм мәнфәгатьләр низагларын көйләү буенча Дәүләт Комитетының дәүләт гражданнар хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү буенча Комиссия утырышында әлеге белдерүне караганда үзем катнашырга җыенам (җыенмыйм)(кирәклесенең астына сызарга кирәк).

“____” _____________ 20____ ел ________________________ ___________________________
(хәбәрнамәне җибәрүче затның имзасы) (имзаны расшифровкалау)